КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Түбән Шытсу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

07.11.2024 №2

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып, «Сез 2025 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Түбән Шытсу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы»:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Шытсу авылында җәяүлеләр күпере салу) дигән сорау буенча 2024 елның 07 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 225 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 118 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 118 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Түбән Шытсу торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Түбән Шытсу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Шытсу авылында җәяүлеләр күпере салу), карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

| | |
|---|---|
| Халык җыенында рәислек итүче, Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы | Б.М.Мәүлетов |